**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# ТОРНАТАШ АВЫЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«01» ноябрь 2019 ел № 01

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Торнаташ авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ**:

1. «2020 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:
- юл ремонтлау;
- светодиод яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру.

2. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина